ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«22 « март 2023 ел № 377

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды бюджет ассигнованиеләрен файдалану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 декабрендәге 1920 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Алдан күрелмәгән чыгымнарны, шул исәптән «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм чыгымнарын финанслау максатыннан һәм кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының резерв фонды бюджет ассигнованиеләрен куллану тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 декабрендәге 1920 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының резерв фонды бюджет ассигнованиеләрен куллану тәртибенең 3 пунктының 3.1 пунктчасын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

- «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция уздыруга бәйле чаралар үткәрүгә»;

«Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә районнары хәрби комиссариаты тарафыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасы формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) бер тапкыр бирелә торган түләү һәм бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән

категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына): бала туганда; җирләүгә (үлгән очракта)»;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе составын (2 нче кушымта) әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
22.03.2023 ел, № 322 карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р. М. | - Башкарма комитет җитәкчесе |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Вафина Э.Ш. | - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| Кадыйров И.Ә. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Сәгыйтова Л.Г. | - Арча район Советының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы |
| Галимуллина Г.Х. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы |
| Шакирова М.Н. | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сафин Р.Р. | - Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Арча һәм Әтнә МР УНД буенча МОНД башлыгы (килешү буенча) |